**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.03.2015 01-02/147

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының Иҗтимагый советы турында нигезләмәсен раслау турында

“Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында” 2014 елның 21 июленнән 212-ФЗ номерлы Федераль Законына, “Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосының Иҗтимагый советы турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 18 ноябреннән 906нчы номерлы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының № 856 (15.10.2011), № 793 (24.10.2013), № 669 (20.09.2014) карарлары белән кертелгән үзгәрешләр) ярашлы рәвештә боерам:

1. Теркәлгән Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының Иҗтимагый советы турында нигезләмәне расларга.

2. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары Р.И.Заһидуллинга йөкләргә.

Министр Л.Ю.Глухова

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 02.03.2015 ел, № 01-02/147 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының
Иҗтимагый советы турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмә

1.1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының Иҗтимагый советы (алга таба – Иҗтимагый совет) Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасында Россия Федерациясе гражданнарының хокукларын һәм иреген, юстиция өлкәсендә дәүләт сәясәтен үткәндә иҗтимагый берләшмәләрнеңхокукларын тәэмин итү белән бәйле сорауларны карауны тормышка ашыручы киңәшмә органы булып тора

1.2. Иҗтимагый советның составы һәм саны Министрлык боерыгы белән раслана.

1.3. Иҗтимагый совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары, шулай ук, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының Иҗтимагый советы турында нигезләмәгә (алга таба – нигезләмә) таяна.

1.4. Иҗтимагый советның карарлары тәкъдим характерында була.

1.5. Иҗтимагый совет үз эшчәнлеген җәмәгать башлангычында алып бара.

1.6. Иҗтимагый үзәкнең эше Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына яраклаштырылып, ирекле нигезгә, ачыклык һәм партнерлык принципларына корылган.

1.7. Иҗтимагый совет үз эшчәнлеген гражданлык җәмгыяте институтлары, дәүләт власте органнары һәм җирле үзидарәвәкилләренең, массакүләм мәгълүмат чараларының үзара кызыксынучанлыгы нигезендә алып бара.

2. Иҗтимагый советның эшчәнлеге максатлары һәм бурычлары

2.1. Иҗтимагый үзәк эшчәнлегенең төп максатлары булып түбәндәгеләр тора:

Россия Федерациясе гражданнарының ихтыяҗы һәм интересларын исәпкә алу, Россия Федерациясе гражданнарының хокукларын һәм иреген, юстиция өлкәсендә дәүләт сәясәтен үткәндә иҗтимагый берләшмәләрнең хокукларын яклау;

Министрлык эшчәнлегендә ачыклык принципларын тормышка ашыру;

Министрлык тәкъдим иткән дәүләт хезмәтләренең сыйфатына җәмәгать контролен көчәйтү, юстиция өлкәсендә ачыклык, законлылык һәм профессионализм принципларын үстерү.

2.2. Иҗтимагый советның бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

юстиция өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

норматив хокукый актлар проектларына иҗтимагый экспертиза үткәрү;

Министрлык әзерли торган норматив хокук актлары проектлары буенча,законда каралган очракларда, алдан фикер алышу;

Министрлык тарафыннан карарлар кабул ителгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу механизмын камилләштерү;

Министрлык эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча җәмәгатьчелекнең мәгълүматлылыгын арттыру.

2.3. Эш нәтиҗәләренә карап, шулай ук, Татарстан Республикасында икътисадый, социаль һәм сәяси ситуацияне исәпкә алып, Иҗтимагый советның максатлары һәм бурычлары үзгәртелә яки тулыландырыла ала.

## 3. Иҗтимагый совет составы

3.1. Иҗтимагый совет гражданнарның, коммерциячел булмаган социаль юнәлештәге оешмаларның тәкъдимнәре нигезендә рәис урынбасары, секретарь һәм Иҗтимагый совет әгъзаларыннан формалаша. Иҗтимагый үзәкнең персональ составын министр раслый.

3.2. Иҗтимагый совет 12 кешедән, аларның ирекле катнашуы нигезендә төзелә.

3.3. Иҗтимагый совет составына Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче гражданнар, шулай ук, коммерциячел булмаган социаль юнәлештәге оешмаларның 21 яше тулган вәкилләре керә ала. Аларның Иҗтимагый совет алдына куелган мәсьәләләр буенча фикер алышу өчен кирәк булган профессиональ сыйфатлары, шул исәптән, юридик белеме, бу сферада эш тәҗрибәсе исәпкә алына.

Иҗтимагый совет составына әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән затлар белән бергә, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тәкъдим иткән затлар да кертелә. Алар Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санының яртысын тәшкил итә ала.

3.4. Россия Федерациясендә дәүләти вазыйфалар, федераль дәүләт гражданнар хезмәте, Татарстан Республикасында һәм Россия Федерациясенең башка субъектларында дәүләти вазыйфалар, муниципаль вазыйфалар, муниципаль хезмәт вазыйфаларын башкаручы затлар, шулай ук, суд карары белән эшкә яраксыз дип табылган, хөкем ителгәннәр, ике гражданлыгы булганнар, “Россия Федерациясенең Иҗтимагый палатасы турында” 2005 елның 4 апреленнән 32нче номерлы Федераль Законның 7нче маддәсенең 2нче бүлегендә күрсәтелгән башка затлар Иҗтимагый совет әгъзалары була алмый.

3.5. Иҗтимагый советның рәисе һәм рәис урынбасары Иҗтимагый совет әгъзалары арасыннан Иҗтимагый советның беренче утырышында ачык тавыш бирү юлы белән, аларга Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санының яртысыннан артыгы тавыш биргән очракта сайлана. Рәисне һәм аның урынбасарын сайлау турында карар Иҗтимагый совет утырышы протоколы белән рәсмиләштерелә.

Иҗтимагый совет рәисе һәм рәис урынбасары вазыйфаларыннан азат ителү мәсьәләсе Иҗтимагый совет тарафыннан аларның шәхси гаризалары яки барлык әгъзаларның биштән беренең тәкъдиме буенча, шулай ук, министр мөрәҗәгате буенча карала.

Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санының яртысыннан артыгы тавыш биргән очракта карар кабул ителгән дип санала.

3.6. Иҗтимагый совет әгъзаларының вәкаләтләре түбәндәге очракта туктатыла:

Иҗтимагый совет составыннан чыгу турында гариза бирүе;

сәламәтлеге начар булу сәбәпле Иҗтимагый совет эшендә катнаша алмау, Иҗтимагый совет эшчәнлегеннән читләшүе яки башка сәбәпләр аркасында;

аңа карата чыгарылган хөкем карарының законлы көченә керүе;

аның законлы көченә кергән суд карары нигезендә эшкә яраксыз яки хәбәрсез югалган дип танылуы;

этик нормаларны тупас бозу – утырышта катнашучы Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителгән Иҗтимагый совет карары буенча;

Россия Федерациясе гражданлыгы өзелү;

җитди сәбәпләр булмаган килеш системалы рәвештә (өч тапкырдан артык) Иҗтимагый совет утырышы эшендә катнашмау;

җитди сәбәпләр белән системалы рәвештә (ике тапкырдан артык) Иҗтимагый совет рәисенең яки рәис урынбасарының йөкләмәсен үтәмәү;

әлеге Нигезләмәнең 3.4 пунктында күрсәтелгән вазыйфаларга керешү.

3.7. Иҗтимагый совет әгъзасы булу Иҗтимагый совет әгъзасының язмача гаризасы нигезендә, Иҗтимагый совет рәисенең яки рәис урынбасарының тәкъдименнән соң, шулай ук, әлеге Нигезләмәнең 3.6 пунктында күрсәтелгән шартлар ачыкланган очракта министр карары белән туктатыла.

Иҗтимагый совет әгъзасы сәламәтлеге аркасында Иҗтимагый совет эшчәнлегендә катнаша алмаган очракта, аңа чыгарылган хөкем карары законлы көченә керсә, Россия Федерациясе гражданы булудан туктаса, ул бу фактлар турында Иҗтимагый советның рәисенә яки рәис урынбасарына хәбәр итәргә тиеш.

3.8. Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләре Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме буенча министр карары белән түбәндәге очракларда туктатыла:

ул җинаять кылуда Россия Федерациясенең җинаять-процессуаль законнарында каралган тәртиптә гаепләнгән булса;

аңа административ арест формасында административ җәза билгеләнсә;

аның дәүләт властеның закон чыгару (вәкиллек) органына депутатлыкка кандидат булып, җирле үзидарә органының сайлап куела торган вазыйфасына кандидат булып, сәяси партия кандидатының вәкаләтле вәкиле яки ышанычлысы булып теркәлүе, шулай ук, аның Россия Федерациясендә референдум үткәрү буенча инициатив төркем составына кертелүе.

## 4. Иҗтимагый совет әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары

4.1. Иҗтимагый совет әгъзасының түбәндәгеләргә хакы бар:

Министрлык инициативасы белән үткәрелә торган бөтен чараларда (утырышлар, киңәшмәләр, “түгәрәк өстәлләр” һәм башкалар) катнаша ала. “Дәүләт сере турында” 1993 елның 21 июленнән 5485-1 номерлы Россия Федерациясе

Законы белән саклана торган мәгълүмат буенча фикер алышынган чаралар гына искәрмә булып тора;

инициатива рәвешендә аналитик язмалар, докладлар һәм башка мәгълүмати-аналитик материаллар әзерләп Иҗтимагый советка тапшыра ала;

Иҗтимагый совет эшенең планына һәм аның утырышларын үткәрү тәртибе буенча Иҗтимагый совет рәисе аша тәкъдимнәр кертә ала;

көн тәртибенә куелган мәсьәләләрне карау өчен Иҗтимагый совет утырышларына чакырылган затларның кандидатуралары буенча тәкдимнәр кертә ала;

Иҗтимагый совет әгъзалыгыннан чыга ала.

4.2. Иҗтимагый совет әгъзасы түбәндәгеләргә бурычлы:

Иҗтимагый совет рәисенең йөкләмәләрен үтәргә;

Иҗтимагый советның әлеге Нигезләмәдә каралган эш тәртибен белергә һәм үтәргә;

Иҗтимагый совет утырышларында шәхсән үзе катнашырга;

Иҗтимагый советка йөкләнгән бурычларны үтәү максатыннан, Иҗтимагый совет оештырган эксперт, эшче төркемнәрдә, комиссияләрдә, башка эшче органнарның эшендә катнашырга.

## 5. Иҗтимагый советның эш тәртибе

5.1. Иҗтимагый совет үз эшен Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме буенча Иҗтимагый совет утырышларында расланган планнар һәм программалар буенча оештыра.

5.2. Иҗтимагый совет эшен планлаштыру Иҗтимагый совет әгъзалары, Иҗтимагый совет рәисе һәм Министрлык тәкъдимнәре нигезендә тормышка ашырыла.

5.3. Иҗтимагый совет утырышлары кварталга бер тапкырдан да сирәгрәк уздырыла алмый. Иҗтимагый совет утырышларында кабул ителгән карарлар Протокол белән рәсмиләштерелә.

5.4. Әгәр анда Иҗтимагый совет әгъзаларының өчтән икедән артыграк өлеше катнаша икән, Иҗтимагый совет утырышы тулы хокуклы булып санала. Иҗтимагый совет әгъзасы, утырышта шәхсән үзе катнаша алмаган очракта, көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча үз тавышын һәм фикерен язмача, факсимиль яки электрон почта аша Иҗтимагый советның башка әгъзасына тапшыра ала. Бу турыда ул Иҗтимагый советның рәисенә, рәис урынбасарына яки җаваплы секретарьга хәбәр итәргә тиеш. Үз тавышын башка Иҗтимагый совет әгъзасына тапшыручы Иҗтимагый совет утырышында катнашучылар санына кушыла.

Иҗтимагый совет карарлары күпчелек тавыш белән кабул ителә.

5.5. Иҗтимагый совет советның утырышларын Иҗтимагый совет рәисе, ул булмаган очракта - Иҗтимагый совет рәисе урынбасары үткәрә.

5.6. Иҗтимагый советның үзенә йөкләнгән максатлар, бурычлар һәм вәкаләтләр буенча кабул ителгән карарлары рекомендация характерында була һәм тиешле затларга Иҗтимагый совет утырышы протоколыннан өземтәләр формасында яки Иҗтимагый совет карары буенча башка юл белән җиткерелә.

5.7. Иҗтимагый совет эше материаллары “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәренең Иҗтимагый совет сайтында яки Министрлык сайты бүлегендә урнаштырыла.

5.8. Иҗтимагый совет рәисе:

Иҗтимагый совет эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелекне тормышка ашыра;

Иҗтимагый совет утырышларын алып бара;

Иҗтимагый совет әгъзаларының тәкъдимнәре нигезендә Иҗтимагый советның эш планын әзерли, аларга үзгәрешләр кертә һәм аларны Иҗтимагый советка раслауга тәкъдим итә;

Иҗтимагый совет утырышларын оештыра;

Иҗтимагый совет утырышы өчен көн тәртибен раслый;

Иҗтимагый совет рекомендацияләрен, протоколларын һәм Иҗтимагый советның башка документларын имзалый;

Иҗтимагый совет утырышының вакытын һәм урынын билгели;

Иҗтимагый совет эшчәнлеге, аңа йөкләнгән максатлар һәм бурычлар кысаларында Иҗтимагый совет әгъзаларына йөкләмәләр бирә;

Иҗтимагый совет исеменнән запросларны, рекомендацияләрне, тәкъдимнәрне, җавапларны, аңлатмаларны һәм мөрәҗәгатьләрне имзалый;

Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итә торганбашка функцияләрне башкара.

5.9. Иҗтимагый совет рәисе урынбасары:

Иҗтимагый совет рәисе рәсми рәвештә була алмаган очракта аның функцияләрен башкара;

Иҗтимагый совет утырышларын әзерләүне оештыра;

Иҗтимагый совет утырышының көн тәртибен төзи һәм аны раслау өчен Иҗтимагый совет рәисенә тапшыра;

Иҗтимагый совет рәисе йөкләмәсе буенча Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле башка функцияләрне башкара.

5.10. Иҗтимагый советның җаваплы секретаре:

утырыш материалларын һәм карар проектларын әзерләүне оештыра;

Иҗтимагый совет әгъзаларына Иҗтимагый совет утырышының урыны һәм вакыты турында, көн тәртибен хәбәр итә, аларны кирәкле мәгълүмати-справка материаллары белән тәэмин итә;

Иҗтимагый совет белән Министрлыкның оештыру эшләре буенча үзара эшчәнлеген тәэмин итә;

Иҗтимагый совет эшчәнлеген документаль-техник яктан тәэминатны тормышка ашыра;

Иҗтимагый совет утырышлары протоколларын рәсмиләштерә һәм кабул ителгән карарларның үтәлешен контрольдә тота;

Иҗтимагый совет утырышлары повесткаларын тутыруда катнаша.

5.11. Иҗтимагый совет әгъзалары Иҗтимагый совет утырышларында тикшереләсе мәсьәләләр буенча әзерләнү өчен эшче һәм эксперт төркемнәренә һәм башка эшче органнарга берләшә алалар, материаллар әзерләү өчен, Иҗтимагый совет рәисе урынбасары белән килешеп, Иҗтимагый совет составына кермәгән белгечләрен тарта алалар.

5.12. Иҗтимагый совет карары буенча Иҗтимагый совет утырышларына Иҗтимагый совет караган мәсьәләләргә ачыклык кертү, кирәкле белешмәләр бирү өчен башкарма органнар, коммерциячел булмаган оешмалар, фәнни учреждениеләр вәкилләре, экспертлар һәм башка белгечләр чакырыла ала. Иҗтимагый совет утырышларында, Иҗтимагый совет чакыруы буенча, аның әгъзасы булмаган массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашырга мөмкин.

5.13. Иҗтимагый советка фикер алышу өчен тәкъдим ителгән материаллар Иҗтимагый совет рәисе урынбасарына Иҗтимагый совет утырышының бу мәсьәлә каралырга тиешле көннән кимендә ун календарь көн алдарак тапшырылырга тиеш. Материалларның соңрак тапшырылу мөмкинлеге Иҗтимагый совет рәисе яки рәис урынбасары белән килешенә.

5.14. Иҗтимагый совет эшчәнлегенең техник ягын һәм оештыру эшләрен Министрлык тәэмин итә.